РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

24 июль 2024 ел Буа шәһәре № 2-64

Җир кишәрлекләрен Татарстан Республикасы милкенә түләүсез тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы

**КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

1. Түбәндәге кадастр номерлы җир кишәрлекләрен:

- 16:14:100203:678, Татарстан Республикасы, Буа муниципаль районы, Түбән Наратбаш авыл җирлеге, Бикмураз авылы адресы буенча урнашкан, 548 кв. м мәйданлы «Казан-Ульяновск - Килдураз - Бикмураз» автомобиль юлына бүлеп бирелгән полоса өчен рөхсәт ителгән файдалану төре белән, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Түбән Наратбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең милек хокукында торучы;
- 16:14:100203:623, Татарстан Республикасы, Буа муниципаль районы, Түбән Наратбаш авыл җирлеге, Бикмураз авылы адресы буенча урнашкан, 393 кв. м мәйданлы «Казан-Ульяновск - Килдураз - Бикмураз» автомобиль юлына бүлеп бирелгән полоса өчен рөхсәт ителгән файдалану төре белән, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Түбән Наратбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең милек хокукында торучы җир кишәрлекләрен Татарстан Республикасы милкенә түләүсез тапшырырга.

2. «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлегенең мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУнә кабул итү-тапшыру актларын әзерләргә.

2.1. Милек хокукын теркәүче органда 16:14:100203:623, 16:14:100203:678 кадастр номерлы җир кишәрлекләрен Татарстан Республикасы милкенә теркәргә.

3. Әлеге карар кабул ителгән көннән законлы көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Буа муниципаль районы башлыгы урынбасары И.Ф. Еремеевка йөкләргә.

Буа муниципаль районы башлыгы,
Совет рәисе Р.Р. Камартдинов